**ГЛАВА**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШЛЫГЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт,

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail:balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.06.2018 Балык Бистәсе штп №54пг

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматлары белән эш итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 12 декабрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматлары белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 975 номерлы карарының 3 пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 42 маддәсендәге 3 өлеше нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматлары белән эш итү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2016 елның 8 сентябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында конфиденциаль характердагы мәгълүмат белән эш итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 116пг номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында конфиденциаль характердагы мәгълүмат белән эш итү тәртибе турындагы Нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Башлык урынбасары И.Г.Ибрагимов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2018 елның 1 июнендәге
54пг номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматлары белән эш итү тәртибе турында Нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында таралу чикләнгән, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә кертелмәгән мәгълүматны үз эченә алган документлар, эшләр, басмалар һәм башка матди мәгълүмат йөртүчеләр (алга таба - документлар) белән эш итү тәртибен билгели.

1.2. Таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә кагылышлы мәгълүмат керә, аның таралуын чикләү хезмәт кирәклеге белән аңлатыла, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарына кергән секрет булмаган мәгълүмат, аңа керү федераль законнар нигезендә чикләнгән.

1.3. Чикләнгән таралу мәгълүматы кертелә алмый:

дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның, иҗтимагый берләшмәләрнең хокукый статусын билгеләүче норматив хокукый актлар, шулай ук гражданнарның хокуклары, ирекләре һәм бурычлары, аларны гамәлгә ашыру тәртибе;

гадәттән тыш хәлләр, куркыныч табигать күренешләре һәм процесслар турында белешмәләр, экологик, гидрометеорология, гидрогеологик, демографик, санитар-эпидемиологик һәм башка торак пунктларның, гражданнарның һәм тулаем халыкның, шулай ук җитештерү объектларының имин яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүмат;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары структурасын тасвирлау, аларның функцияләре, эшчәнлек юнәлешләре һәм рәвешләре, шулай ук аларның адресы;

билгеләнгән тәртиптә карап тикшерелгән гражданнар һәм юридик затларның гаризалары һәм мөрәҗәгатьләре буенча карарлар;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты үтәлеше һәм башка муниципаль ресурслардан файдалану, икътисадның торышы һәм халыкның ихтыяҗлары турында мәгълүматлар;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының китапханә һәм архивларның ачык фондларында, мәгълүмат системаларында туплана торган, гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм бурычларын тормышка ашыру өчен кирәкле документлар.

1.4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба-җитәкче) үз компетенциясе чикләрендә билгели:

башка органнарга һәм оешмаларга таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын тапшыру тәртибе;

таралу чикләнгән мәгълүмат йөртүчеләрдән “Хезмәт урынында файдалану өчен " тамгасын төшерү тәртибе;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының тиешле җирле үзидарә органында таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын яклауны оештыру, шулай ук аның структур бүлекчәләрендә һәм ведомство карамагындагы оешмаларда.

1.5. Таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган документларда “Хезмәт урынында файдалану өчен " (“ХУФ”) тамгасы куела.

1.6. “Хезмәт урынында файдалану өчен " тамгасын бирү турындагы карар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органының башкаручы, структур бүлекчәсе җитәкчесе яисә документка кул куйган җитәкче тарафыннан кабул ителә.

Мәгълүматны таратуның чикләнгән разрядына кертү яки кертмәү турында карар кабул иткән вазыйфаи затлар моның өчен шәхси җаваплылык тоталар.

1.7. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы бетерелгән очракта, таралуы чикләнгән хезмәт мәгълүматыннан алга таба файдалану турында карар тиешле ликвидация комиссиясе тарафыннан кабул ителә.

## II. Таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган документлар белән эш итү тәртибе

2.1. Таралуы чикләнгән документларда “Хезмәт урынында файдалану өчен” (“ДСП”) тамгасы һәм нөсхәнең номеры документның беренче битенең иң югары почмагында күрсәтелә, басманың титул битендә һәм тышлыгында, шулай ук мондый документларны озату хатының беренче битендә.

Таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган документның һәр нөсхәсенең беренче битенең арткы ягында документны башкаручының фамилиясе, инициаллары һәм телефоны, документны булдыру (бастыру) датасы күрсәтелә.

2.2. Таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган документлар хәрәкәтен кабул итү, теркәү һәм исәпкә алу (күбәйтелгән документларны исәпкә алу) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла, аңа хезмәт корреспонденциясен кабул итү һәм исәпкә алу йөкләнгән. Документлар Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында таралу чикләнгән мәгълүматны яклау буенча кирәкле таләпләрне үтәп теркәлә, шулай ук таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган документларны исәпкә алу журналында теркәлә

(таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган электрон йөртүчеләрне исәпкә алу журналында) (алга таба – исәпкә алу журналы). Документлар хәрәкәтен исәпкә алу (күбәйтелгән документларны исәпкә алу) хисап журналында әлеге Нигезләмәнең кушымтасына ярашлы рәвештә чагылдырыла.

2.3. Таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган булдырылган һәм имзаланган документлар:

теркәү өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органының хезмәт корреспонденциясен кабул итү һәм исәпкә алу йөкләнгән структур бүлекчәсенә тапшырыла, шул ук вакытта караламалар юк ителә;

башка хезмәт корреспонденциясеннән аерым исәпкә алына;

“ДСП” индексы документының теркәү номерында күрсәтелеп теркәлә;

башкаручыларга хисап журналында кул куйдырып җитәкче резолюциясе нигезендә тапшырыла;

фельдъегерлык элемтәсе, заказлы яки кыйммәтле почта юлламалары, курьер аша илтеп җиткерү юлы белән җибәрелә;

җитәкченең резолюциясе нигезендә генә тиражлана;

бикләнә торган шкафларда (ящикларда, саклагычларда) саклана;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органының җаваплы структур бүлекчәсенә саклау өчен алар белән эш тәмамланганнан соң, бу хакта белешмәләр исәпкә алу журналында күрсәтелеп, башкаручылар тарафыннан тапшырыла.

2.4. Күбәйтелгән документларны исәпкә алу нөсхәләп  башкарыла.

2.5. Үзенең гамәли әһәмиятен югалткан һәм тарихи кыйммәтләре булмаган “ДСП” тамгасы булган документларны юк итү акт буенча башкарыла.

2.6. Таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган документларны исәпкә алу өчен җаваплы хезмәткәр алышынганда әлеге документларны кабул итү-тапшыру акты төзелә, ул җитәкче тарафыннан раслана.

2.7. Таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган документларның булу-булмавын тикшерү җитәкченең боерыгы (күрсәтмәсе) белән билгеләнә торган комиссия елына бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә үткәрелә. Комиссия составына таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган документларны исәпкә алу һәм саклау өчен җаваплы хезмәткәрләр кертелә. Тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә.

2.8. Таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган документларны югалту фактлары буенча хезмәт тикшерүе үткәрелә.

2.9. Югалган документлар, эшләр һәм басмаларга “ДСП” дигән тамга белән акт төзелә, аның нигезендә исәпкә алу журналларында тиешле билгеләр ясала.

## III. Таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган документлар белән эш итү тәртибен бозган өчен җаваплылык

3.1. “ДСП”тамгасы белән документларны теркәү, исәпкә алу, күбәйтү һәм адресатка җиткерүнең дөреслеген тәэмин итү өчен җаваплылык Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесенә йөкләнә, аңа хезмәт корреспонденциясен кабул итү һәм исәпкә алу йөкләнгән.

3.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органының структур бүлекчәсендә “ДСП” тамгасы булган документларны саклау өчен җаваплылык тиешле структур бүлекчә җитәкчесенә йөкләнә.

3.3. Таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын тараткан өчен, шулай ук мондый мәгълүмат булган документлар белән эш итү тәртибен бозган өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре дисциплинар яки законнарда каралган башка җаваплылыкка тартыла.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы җирле үзидарә
органнарында таралу чикләнгән хезмәт
мәгълүматы белән эш итү тәртибе турында
Нигезләмәгә кушымта

## Таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган керүче документларны исәпкә алу журналы (“Хезмәт урынында файдалану өчен” (“ДСП”) тамгасы булган документлар)

| Тәртип буенча исәпкә алу номеры | Теркәү датасы | Керү N | Имзаланган | Нөсхәләр саны | Битләр саны | Нөсхә N | Адресат | Резолюция буенча җибәрү | | Алу турында имза һәм реестрның датасы/номеры һәм датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | N экземпляра | Адресат | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | | | | | | | | | | | |

## Таралу чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган чыгучы документларны исәпкә алу журналы (“Хезмәт урынында файдалану өчен” (“ДСП”) тамгасы булган документлар)

| Тәртип буенча исәпкә алу номеры | Теркәү датасы | Чыгу N | Имзаланган | Нөсхәләр саны | Битләр саны | Нөсхә N | Адресат | Алу турында имза һәм реестрның датасы/номеры һәм датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| | | | | | | | | | |

## Таралу чикләнгән электрон йөрткечләрне исәпкә алу журналы (“Хезмәт урынында файдалану өчен” (“ДСП”) тамгасы булган электрон йөрткечләр)

| Исәпкә алу N | Исәпкә кую датасы | Төр | Күләм | Уникаль таныклагыч | Бирү датасы | Алучының ФИАи, имзасы | Бирүченең ФИАи, имзасы | Йөрткечне юк итү турында билге |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |